# Г.Тукай
## “Ана догасы” шигырен өйрәнү

- **Изрәп йоклый сабый. Бит очлары**
- **Кояш кебек балкып яналар.**
- **Көйләр көйләп бишек тирбәткәндә**
- **Нәрсә уйлый икән аналар?**
- **Баласының якты киләчәген**
- **Уйлыйлардыр безнең аналар.**

- “ Уч төбендә тәбә пешереп ашатсаң да, әниең каршында изге бурычыңны үти алмыйсың”.

# Габдулла Тукай-татар халкының бөек шагыйре



Мөхәммәтгариф




Мәмдүдә



Кечкенә Тукай дүрт айда әтисез, дүрт яшьтә әнисез кала. Ятимлек ачысын бик иртә татый.



Кечкенә Габдулланың әнисе Мәмдүдә Сасна авылы мулласына кияүгә чыга һәм соңрак аны үз янына алдыра.



# “Исемдә калганнар” әсәрендә болай сурәтли:

- ”Әнкәмнең женазасын күтәреп алып киткәннәрен сизгәч, яланаяк, яланбаш хәлемдә, капка астыннан үкереп җылый – җылый йөгереп чыгып, әнкәйне кайтарыгыз, әнкәйне бирегез! – дип шактый гына җир мәет күтәрүчеләрдә калмый барганмын”.

- Исәнлек – саулыгын сорап,
- Дога кылам.
- Әниемнән аермасын
- Беруk Ходам.

- Дога – 1. Дин тотучыларның Аллага, изгеләргә ялварып, теләкләр теләп мөрәҗәгать итүе.
- 2. Аллага, изгеләргә мөрәҗәгать иткәндә әйтелә торган һәм сүзләре алдан билгеле булган текст.

- <u>**Коръәннән**</u>
- **Ата – аналарын риза кылучы балалардан Аллаһы Тәгалә дә риза булыр.**
- **Ата – аналарыгызга игелек итегез, сезгә дә балаларыгыз игелек итәр.**
- **Әгәр ата –ананңның берәрсе яки икесе дә синең янында картлыкка ирешсәләр, син аларга “уф” дип тә әйтә күрмә, аларга кычкырма, ә яхшы, мөлаем сүзләр генә сөйлә.**

- <u>Сүзлек өстендә эш</u>
- Вә -һәм
- Уйку –йокы
- Фәкать – тик
- Ясту – кичке намаз вакыты
- Яд итә - исенә төшерә
- Тәңре – Алла
- Намазлык  - намаз укыганда басып укый торган җәймә (күрсәтелә)

# АНА ДОГАСЫ

- Менә кич. Зур авыл өстендә чыкты нурлы ай калкып,
- Көмешләнгән бөтен өйләр, вә сахралар тора балкып.
- 
- Авыл тын; иртәдән кичкә кадәр хезмәт итеп арган
- Халык йоклый — каты, тәмле вә рәхәт уйкуга талган.
- 
- Урамда өрми этләр дә, авыл үлгән, тавыш-тын юк;
- Авыл кырыенда бер өйдә фәкать сүнми тора бер ут.
- 
- Әнә шул өй эчендә ястүеннән соңра бер карчык
- Намазлыкка утырган, бар җиһаннан күңлене арчып;
- 
- Күтәргән кул догага, яд итә ул шунда үз угълын:
- Ходаем, ди, бәхетле булсайде сөйгән, газиз угълым!
- 
- Тамадыр мискинәмнең тамчы-тамчы күзләреннән яшь:
- Карагыз: шул догамы -инде тәңре каршына бармас?
- 

- 1.Анаң өчен уч төбендә тәбә куырсаң да бурычыңны кайтара алмассың.
- 2.Ана яхшылыгын авырсаң белерсең.
- 3.Анасына өргән эт бүре авызына төшәр.
- 4.Өйнең яме ана белән.
- 5.Үз анасын зурлаган, кеше анасын хурламас.
- 6.Ана балага авызыннан өзеп каптырыр.
- 7. Ана күңеле балада, бала күңеле далада.
- 8.Ата-ананы тыңлаган — адәм булган,
- тыңламаган — әрәм булган.
- 9.Ата-анасына игелек күрсәтмәгән,
  Олыгайгач үзе дә игелек күрмәс.
- 10 Ата-анасын хурлаган үзен хурлаган булыр.

# Өй эше

- *Үзегезне үсеп җитеп әниләрегездән читтә дип, хис итегез һәм әниегезгә хат языгыз.*

- Ямьсез күреп, ямьсез дия күрмә -
- Һәр чәчәкнең аның төсе бар.
- Сөйкемсез сөяк буламы? –
- Һәркемнең әнисе бар.
- Бәләкәйне бәләкәй ди күрмә -
- Һәр җимешнең аның төше бар.
- Кеше бәләкәй буламы? –
- Кешенең әнисе бар.
- Баласына сүз тидермәс өчен,
- Газиз җанын бирер кеше бар.
- Бер бәләкәй генә адәмгә дә
- Берәүләрнең таудай хисе бар!...
- “Мәрхәмәтле бул балам” – диеп,
- Дога укып торыр кеше бар.
- Кимсетә күрмә кешене –
- Кешенең әнисе бар.
- *Минем дә әнием бар,*
- *Синең дә әниең бар,*
- *Аның да әнисе бар*
- Исән булсын әниләр!